**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЕТРӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IX УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 16**

Метрәй 24 февраль2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән территориясендә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»**

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, Метрәй авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затлар милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны рациональ файдалану, саклау һәм яңадан җитештерү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән территориясендә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Ф.Я.Гизтдинов

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районының
24 февраль №16 номерлы
Метрәй авыл җирлеге Советы
карарына кушымта

**НИГЕЗЛӘМӘ**
**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән территориясендә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында**

Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексының 15 ст., Россия Федерациясе Урман кодексы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 61, 68, 77 ст, Метрәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, халыкның экологик иминлеген тәэмин итү максатларында эшләнде һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлеге (алга таба - авыл җирлеге) территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә керми торган яшел утыртмаланы кисү тәртибен билгели.

**1. Төп төшенчәләр**

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Яшел утыртмалар – табигый һәм ясалма чыгышлы агач, куак һәм үләнле үсемлекләр (шул исәптән парклар, скверлар, бакчалар, газоннар, чәчәклекләр, шулай ук аерым торучы агачлар һәм куаклар).

Табигый территорияләр - бердәм географик (климат) шартларында формалашкан җир рельефының, туфракның, үсемлекләрнең билгеле бер төрләрен үз эченә алган хуҗалык эшчәнлегенә кулланылмаган яисә аз кулланылган территорияләр.

Яшелләндерелгән территорияләр – табигый чыгышлы үсемлекләр кишәрлекләре, ясалма рәвештә булдырылган яшелләндерү объектлары (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), төрле функциональ билгеләнештәге аз төзелешле, өслекнең кимендә 50 процентын үсемлекләр капламы биләгән җир кишәрлекләре урнашкан территорияләр.

Урманга әверелгән территорияләр – табигый тишелеп чыккан урман үсемлекләре белән капланган төрле функциональ билгеләнештәге табигать территорияләре кишәрлекләре.

Агач – 1,3 м биеклектә 5 см дан да ким булмаган диаметрлы ачык беленеп торган кәүсәле, үсентеләрдән тыш, үсемлек.

Куак – туфрак өслегеннән үк тармакланган, күпьеллык күпкәүсәле (агачтан аермалы буларак) үсемлек.

Үлән капламы – газон, табигый үлән үсемлеге.

Әрәмәлекләр – нинди дә булса урында куе булып үсә торган үсемлекләр, куаклар.

Яшел массив – бердәм түбә барлыкка китерүче 50 данәдән дә ким булмаган зур (15 елдан күбрәк) агач үсә торган территория кишәрлеге.

Яшел утыртмаларга зыян китерү – яшел утыртмаларга үсешен туктатуга китерми торган зыян китерү, шул исәптән ботакларга, тамыр системасына механик зыян китерү, кайрының бөтенлеген, тере туфрак катламын бозу, яшел утыртмаларны яисә тамыр зонасындагы туфракны зарарлы матдәләр белән пычрату, ут төртү яки башка йогынты ясау.

Яшел утыртмаларны юкка чыгару (югалту) – яшел утыртмаларның үсешен туктатуга китергән кисү яки башка зыян китерү.

Компенсация рәвешендәге яшелләндерү – юк ителгән яки зарарланган яшел утыртмаларны 2 коэффициенты белән яңадан утырту.

## 2. Яшел утыртмаларны саклауның төп принциплары

Муниципаль берәмлек территориясендә үсә торган яшел утыртмалар саклагыч, рекреацион, эстетик функцияләр башкара һәм алар сакланырга тиеш.

2.1. Авыл җирлеге территориясендә (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) урнашкан барлык яшел утыртмалар (агачлар, куаклар) якланырга тиеш.

2.2. Авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне саклау һәм үстерү өчен шартлар тәэмин итү бурычлары түбәндәгеләргә йөкләнә:

2.2.1. оешмаларга үзләре белдергән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән кишәрлекләрдә – әлеге оешмалар җитәкчеләренә;

2.2.2. милектәге яки арендага алынган кишәрлекләрдә – юридик затларга, гражданнарга-милекчеләргә яки арендаторларга.

2.3. Яшел утыртмалар урнашкан җир кишәрлекләренең милекчеләре, кулланучылары һәм арендаторлары яшел утыртмаларның сакланышын яшел утыртмаларны тиешенчә карауны тәэмин итәргә тиеш.

2.4. Әлеге Нигезләмә барлык гражданнарга һәм, милек формаларына бәйсез рәвештә, авыл җирлеге территориясендә агач-куак үсентеләрен кисүгә бәйле рәвештә проектлауны, төзүне, ремонтлауны һәм башка эшләрне алып баручы оешмаларга кагыла.

2.5. Авыл җирлеге территориясендә хуҗалык, шәһәр төзелеше һәм башка эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән яшел утыртмаларны саклау таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

2.6. Җир кишәрлеген сайлау акты, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне оештыруга проект алды һәм проект документациясендә яшел утыртмаларның торышы турында тулы һәм дөрес белешмәләр һәм проектлана торган объектның яшел утыртмаларга йогынтысын тулысынча бәяләү булырга тиеш.

2.7. Яшелләндерелгән территорияләрдән һәм яшел массивлардан яшел утыртмаларның тереклек эшчәнлеген тәэмин итми торган файдалану рөхсәт ителми.

## 3. Яшел утыртмаларны (агачларны, куакларны) кисү тәртибе

3.1. Авыл җирлеге территориясендә яшел утыртмаларны рөхсәтсез кисү тыела.

3.2. Авыл җирлеге территориясендә агачларны һәм куакларны кисү рөхсәт нигезендә башкарыла. Кисүгә рөхсәт авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.
3.3. Яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт алу өчен, мөрәҗәгать итүче Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә билгеләнгән формада (1 нче кушымта) хат-гариза бирә, анда утыртмаларның саны, исеме, аларның торышы, чикләнгән кисү үткәрелү урыны һәм аны нигезләү күрсәтелгән булырга тиеш. Гаризага түбәндәге документлар беркетеп бирелә:
3.3.1. Шәхесне раслаучы документлар;
3.3.2. Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш иткән очракта);
3.3.3. Киселергә тиешле яшел утыртмаларны да тамгалап якындагы корылмаларга яки башка ориентирларга кадәр җир кишәрлеге схемасы;
3.3.4. Әгәр җир кишәрлеге Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса, җир кишәрлегенә хокук билгели торган һәм хокук раслый торган документларның расланган күчермәләре;
3.3.5. Биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга эләгә торган яшел утыртмалар киселгән очракта, расланган проект документлары;
3.3.6. Кисү эшләре кагыла торган территорияләрнең хуҗалары белән яшел утыртмаларны кисү һәм күчереп утырту шартларын килештерү;
3.3.7. Утыртмаларны утыртканда яки күчереп утыртканда инженер челтәрләре вәкилләре белән җир эшләрен башкаруга ордер ачуны килештерү.
3.4. Авыл җирлеге Башкарма комитеты, хат-гариза кергәннән соң, Гариза бирүчегә әлеге эш төрен үткәрүгә рөхсәте булган махсуслаштырылган оешмага түбәндәгеләрне алу өчен мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә:
3.4.1. яшел утыртмаларны исәпләү исемлеген (ведомосте);
3.4.2. кисәргә тиешле агач-куак үсемлекләренең агач санын, төрен, категориясен билгеләү максатларында төзелә торган яшел утыртмаларны табигый техник тикшерү акты;
3.4.3. киселгән агач бәясен (өчен түләүне) исәпләүне. Киселгән агач өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары белән расланган ставкалар нигезендә аерым исәпләнә.
Югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару Гариза бирүче хисабына башкарыла.
Рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты - 90 көн.
3.5. Авыл җирлеге Башкарма комитеты Гариза бирүченең хат-гаризасы, яшел утыртмаларны табигый техник тикшерү акты, киселгән агач өчен бәяне (түләүне) исәпләп чыгару нигезендә авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт бирү турында авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең күрсәтмә проектын әзерли.
3.6. Эшләр башкаруга рөхсәт алганда, аның мәнфәгатьләрендә яшел утыртмалар юкка чыгарыла торган Гариза бирүче, әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларны кискән өчен түләүләр кертергә һәм компенсация рәвешендә яшелләндерүнең тәртибен раслый торган документларны тапшырырга тиеш.
3.7. Агач һәм куакларны кискән өчен түләү Гариза бирүче тарафыннан Авыл җирлеге бюджетына күчерелә.

3.8. Яшел утыртмаларны кисү эшләре билгеләнгән нормаларга һәм кагыйдәләргә туры китереп, Гариза бирүче акчасы хисабына башкарыла. Аттестацияләнгән белгечләргә генә агачны кисү рөхсәт ителә.
3.9. Егу, кисү, киселгән яшел утыртмаларны һәм кискәннән калган калдыкларны төяү һәм чыгару эшләр башланганнан соң өч көн эчендә Гариза бирүче хисабына башкарыла. Киселгән яшел утыртмаларны һәм кискәннән калган калдыкларны эш урынында саклау тыела.
3.10. Кисү урынына якын территориядә газонга, яшел утыртмаларга зыян тигән очракта, эш башкаручы аларны территория хуҗасы һәм контрольлек итүче органнар белән аларның компетенциясе чикләрендә килештерелгән вакытта, әмма зыян килгән вакыттан ярты елдан да соңга калмыйча, мәҗбүри торгыза.
3.11. Агачны кискән өчен түләмичә генә агач һәм куакларны кисү Авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителергә мөмкин:
3.11.1. яшел үсентеләрне тәрбияләү, санитар кисүләр һәм реконструкцияләү өчен кисүләр үткәрү;
3.11.2. авария һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау вакытында;
3.11.3. әгәр дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелек үзәге бәяләмәсе булса, торак һәм җәмәгать биналарында ут режимын бозучы агачларны һәм куакларны кискәндә;
3.11.4. авария хәлендәге (егылу куркынычы тудыручы, тамыры корыган) агачларны һәм куакларны кискәндә.
3.12. Югарыда күрсәтелгән очракларда яшел үсентеләрне кисүне гамәлгә ашыручы Гариза бирүчегә авыл җирлеге Башкарма комитеты белән килештерелгән урыннарда компенсация рәвешендә яшелләндерү үткәрергә кирәк.
3.13. Авария хәлендәге, тамыры корыган һәм хәвеф-хәтәр куркынычы тудыручы яшел утыртмалар комиссия тикшерүе нигезендә 2 нче кушымтада күрсәтелгән акт нигезендә киселә.
3.14. РФ Урман кодексының 20 статьясына тәңгәлләштереп, гражданга яисә юридик затка милеккә тапшырганнан соң җир кишәрлегендә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә яки табигый рәвештә барлыкка килгән агач-куак үсемлекләре аның белән үзе теләгәнчә хуҗа була, файдалана һәм җитәкчелек итә торган милке булып тора.
3.15. Яшел утыртмаларны рөхсәтсез кисү яисә юкка чыгару дип түбәндәгеләр танылa:
3.15.1. рөхсәтсез яки рөхсәт белән, әмма рөхсәттә күрсәтелгән кишәрлектә, санда һәм рөхсәттә күрсәтелгән токымнар булмаган агачларны һәм куакларны кисү;
3.15.2. ут төртү яки ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә агачларны һәм куакларны юк итү яки аларга зыян китерү;
3.15.3. кәүсәне боҗралау яки төпләү (подсечка);
3.15.4. үсә торган агачларга һәм куакларга үсешне туктату дәрәҗәсенә кадәр зыян китерү;

3.15.5. агачларга һәм куакларга агып җыела торган сулар, химик матдәләр, калдыклар һ. б. шуның ишеләр белән зыян китерү;
3.15.6. тамыры корыган агачларны рөхсәтсез кисү;
3.15.7. үсә торган агачларга һәм куакларга башка зыян китерүләр.
3.16. Дәүләт урман фондында булган агачларны һәм куакларны кисү махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан бирелгән рөхсәтләр нигезендә гамәлгә ашырыла.
3.17. Әлеге Нигезләмәне бозып, агачларны һәм куакларны юк итү рөхсәтсез кисү булып санала һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ һәм җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш. Әлеге Нигезләмә кагыйдәләрен үтәү авыл җирлеге территориясендә барлык гражданнар, оешмалар һәм учреждениеләр өчен мәҗбүри.

## 4. Компенсация рәвешендә яшелләндерү

4.1. Компенсация рәвешендәге яшелләндерү рөхсәт ителгән кисү, законсыз рәвештә яшел утыртмаларга зыян китерү яки аларны юк итү очракларында гамәлгә ашырыла. Компенсация рәвешендәге яшелләндерү агачлар, куаклар һәм газоннар утырту өчен уңайлы якын сезонда, әмма яшел утыртмаларга зыян китерү яки аларны юк итү факты ачыкланганнан соң бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.
4.2. Компенсация рәвешендәге яшелләндерү аларның мәнфәгатьләрендә яки аларның хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә яшел утыртмаларга зыян килгән яки юк ителгән гражданнар яисә юридик затлар акчалары хисабына башкарыла.
4.3. Әлеге Нигезләмә нигезендә, яшел утыртмаларга китерелгән зыян табигый формада кайтарылырга тиеш - компенсация рәвешендә яшелләндерү: юк ителгән яшел утыртмаларны 2 коэффициенты белән яңадан торгызу.

## 5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда яшел утыртмаларны саклау

5.1. Авыл җирлегендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру яшел утыртмаларны саклау таләпләрен үтәп алып барыла.
5.2. Яшелләндерелгән территорияләрдә, шул исәптән яшел массивларда, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне үстерү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә аларның максатчан билгеләнешенә бәйле булмаган төзелеш алып барылырга һәм кулланылырга тиеш түгел.
5.3. Яшел утыртмалар утыртылган җир кишәрлекләрендә төзелеш алып барганда, проект документациясендә киселергә тиешле яшел утыртмаларга бәя булырга тиеш. Бу очракларда зыянны каплау әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә киселгән агач өчен түләүне алдан кертү һәм компенсация рәвешендә яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 6. Эшмәкәрлек эшчәнлеген башкарганда яшел утыртмаларны саклау

6.1. Яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда авыл җирлеге Башкарма комитеты рөхсәтеннән башка сәүдә һәм башка эшмәкәрлек эшчәнлеге,

эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела.
6.2. Яшел территорияләрдә һәм яшел массивларда эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырганда, шартлау куркынычы тудыра торган, янгын куркынычы тудыра торган һәм агулы матдәләр куллану, территорияне пычрату һәм чүпләү, яшел утыртмаларга зыян китерергә яки аларны юк итәргә сәләтле башка гамәлләр тыела.

## 7. Административ җаваплылык

7.1. Әлеге Нигезләмәне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы.

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Метрәй авыл җирлегенең
Россия Федерациясе дәүләт урман
фонды җирләренә кермәгән
территориясендә яшел утыртмаларны
кисү тәртибе турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим
муниципаль районы Метрәй
авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе
_________________________________________

_________________________________________

_________________________________________

_________________________________________
(оешманың исемен яки Ф.И.А., адресын күрсәтергә )

МЕТРӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ АГАЧ-КУАК ҮСЕМЛЕКЛӘРЕН ЧИКЛЕ КҮЛӘМДӘ КИСҮГӘ
ГАРИЗА

________________________________________________________________________
(оешманың исемен яки Ф.И.А. һәм җир кишәрлегенә хокук төрен күрсәтергә)
урнашкан җир кишәрлегендәге һәм _________________________________________
(торак пунктны күрсәтергә)
җирләрендә урнашкан агачларны, куакларны, агач-куак үсемлекләренең (кирәклесенең астына сызарга) кисүне рөхсәт итүегезне сорыйм.
Җир кишәрлеге түбәндәгеләр булу белән характерлана:
агач ______________________________ данә;
куаклар ______________________________ данә.
Җир кишәрлеген үзләштерү һәм төзекләндерү барышында агач кискән өчен түләүне гамәлгә ашырырга һәм дендроплан нигезендә агач-куак үсемлекләрен компенсация рәвешендә утыртуны уздырырга сүз бирәм.

_______________ ________________
Ф.И.А. (Имза)

Дата _____________

Кушымталар:
1. Беренчел-рөхсәт документлары.
2. Киселергә тиешле яшел утыртмаларның төрен һәм санын тамгалап, җир участогы планы.

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән территориясендә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында Нигезләмәгә
2 нче кушымта

ЯШЕЛ УТЫРТМАЛАРНЫҢ КИСЕЛЕРГӘ ТИЕШ БУЛУЫН ТАНУ ТУРЫНДА АКТ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Башкарма комитеты
«_____»_________ ________ ел

Түбәндәге составтагы Комиссия:
1.____________________________________________________________________
(Ф. И. А., вазыйфасы)
2.____________________________________________________________________
(Ф. И. А., вазыйфасы)
3.____________________________________________________________________
(Ф. И. А., вазыйфасы)
яшел утыртмаларны тикшерүне уздырды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр билгеләнде:
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________

Нәтиҗә:
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
___

Комиссия әгъзалары:

_______________ _____________________________
(имза) (Ф. И. А.)
_______________ _____________________________
(имза) (Ф. И. А.)
_______________ _____________________________
(имза) (Ф. И. А.)